КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 779

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә, VIII бүлек исемендә «2020 елда» сүзләрен «2020 – 2023 елларда» сүзләренә алыштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин